Хәмидуллина, Р. Мулла иле Насыйри эзләрен саклый / Р. Камалова // Мәйдан. – 2025. – №3 (280). – Б. 154-157.




# Мулла Иле
# Насыйри эзләрен саклый

**Яшел Үзән районы һәм әлеге районда урнашкан Мулла Иле авылы белән таныша аласыз.**

Яшел Үзән – Идел елгасының ике ярына да урнашкан бердәнбер район. Районда бүгенге көндә 166 меңнән артык кеше яши.

Ул көнбатышта – Чуаш Республикасы, төньякта – Марий Эл, төньяк-көнчыгышта – Татарстанның Биектау районы, көньяк-көнчыгышта – Югары Ослан, көньяк-көнчыгышта – Кайбыч, көнчыгышта Казан белән чиктәш. Район территориясеннән Зөя елгасы (Иделнең уң кушылдыгы) һәм Сумка (Иделнең сул кушылдыгы) ага. Районның мәйданы 1396 квадрат км. Яшел Үзән – Татарстанда халык саны буенча бишенче урынны алып торган шәһәр.

1865 елда бүгенге Яшел Үзән урынында Кабащиче авылы нигезләнә. 1890 елда биредә 104 кеше яшәгән. Аның янәшәсендә урман кисү заводлары эшләгән. 1897 елда авыл Паратск яки Паратск затоны дип үзгәртелә. Авыл Идел буйлап бара торган елга судноларын ремонтлау һәм кышлату урынына әйләнә. Затон судомастерлары булачак Горький исемендәге завод өчен төп нигез булып хезмәт иткәннәр.

1913 елның 11 июлендә бистә янында Идел аша тимер юл күпере ачыла, ә бистәдә бер станция оештырыла. 1928 елда Паратскины Яшел Үзән эшчеләр бистәсе дип үзгәртәләр. Шәһәр статусын ул 1932 елда ала.

Яшел Үзәндә җитештерүнең иң мөһим юнәлешләре булып суднолар һәм машина төзелеше, агач эшкәртү санала. Шулай ук район территориясендә химия лабораторияләре өчен савыт-саба җитештерү дә үсеш алган.

Яшел Үзән районы – Татарстанда туристларны иң күп кабул итә торган төбәкләрнең берсе, биредә Зөя утрау-шәһәрчеге урнашкан.

Яшел Үзән районыннан тел галиме, фольклорчы Каюм Насыйри, Татарстанның халык җырчысы Усман Әлмиев, Мәскәүдә татар театрын оештыручы Газиз Айдарский, әдәбият галиме Резеда Ганиева һәм башка бик күп билгеле шәхесләр чыккан. (Мәгълүматлар интернеттан тупланды.)

Боргаланып аккан Зөя елгасыннан ерак түгел, табигатьнең матур бер почмагында, барлык хозурлыгы белән җәелеп яткан үзәнлектә бер борынгы авыл бар. Ул – Яшел Үзән районының Мулла Иле авылы.

Туган авылымның тарихы ерак гасырларга барып тоташа: ул 1240 еллар тирәсендә нигезләнгән.

Мулла Иле атамасы тарихи белешмәләрдә шактый еш очрый. Авыл атамасы Молнина – Молвина – Мулла Иле дигән төрдәшләре белән Казан ханлыгы чорында ук кулланылган. 1565–1567 ел мәгълүматларын үз эченә алган Зөя өязенең теркәү кенәгәсендә Мулла Иле авылы да искә алына.

Каюм Насыйри үзенең «Зөя өязе авыллары» дигән хезмәтендә Мулла Иле авылының тарихына мөнәсәбәтле мәгълүматлар урнаштырган: «Бу Мулла Иленең асылы бик күптәндер. Монда бер Муллагол дигән кеше Болгардан килеп утыргандыр. Алар әүвәл

килгәндә берничә кеше булып килгәннәр. Бәгъзесенең исемнәре мәгълүм түгел. Аларның берсе Муллагол дигән кеше».

500 гә якын хуҗалыгы булган Мулла Иле авылы халкының дүрттән өч өлеше Муллагол бабай нәселеннән.

Мулла Иле халкы элек-электән игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. Бакчачылык һәм яшелчә үстерү белән халык аз мавыккан.

Мулла Иле искиткеч матур табигать кочагында урын алган. Авылдан ерак түгел генә үз көенә агып яткан Зөя елгасы, аңа килеп кушылучы Әрә, Комсу, Кухмар, Мөңгер, Олы Тамак (Алтамак) суларына, күккә омтылган калкулык-үрләргә, иксез-чиксез басу-кырларга сокланмый мөмкин түгел. Шунысы игътибарга лаек, аларның һәрберсенең үз исем-атамасы бар. Авылның эчендә дә түгәрәк күлләр шактый: Кирәмәт күле, Урта күл, Мәчет күле, Чупак күле, Паравай күле.

Авыл тарихында революция, гражданнар сугышы, 1921 елгы ачлык, 1926 елда авылны су басу, коллективлаштыру чоры, 1930 елгы көчле янгында 38 йорт яну, Сталин репрессияләре, Бөек Ватан сугышы кебек авыр фаҗигаләр тирән эз булып уелып калган. Авылда бу тарихи зилзиләләр кагылмаган бер генә йорт та юктыр.

Элек авылда өч мәчет эшләгән, 1920 елларда дүртенчесен күтәргәннәр. Ә Совет чорында муллаларны Себергә куганнар. Мәчетләрнең берсе янган, икенчесендә – клуб, өченчесендә – ашлык саклау урыны, соңрак балалар бакчасы ачканнар.

Мәчетләр ябылгач та авыл халкы диннән йөз чөермәгән. Муллалык вазифасын ак бабайлар үз кулларына алган. Олыларны шәригать кушканча җирләгәннәр, ата-бабадан килгән гореф-гадәтләрне ташламаганнар. Мәчет биналарын да хәлләреннән килгәнчә сакларга тырышканнар. Авылның түбән башында 1873 елда Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең кушуы буенча Мөхәммәтҗан Казаков төзетеп калдырган мәчет бүген дә халыкка хезмәт итә. Илленче елларда манарасы төшерелгәннән соң, 1990 елда авылның мәгърифәтле кешеләре тырышлыгы белән манара яңадан күтәрелде. Бүгенге көндә авылның ике башындагы ике мәчеттән биш вакыт азан тавышы яңгырап тора.

Татар совет әдәбиятының классигы Һади Такташның, авылда булып киткәннән соң, «Совет председателеме, мулламы, әллә бер колгамы?» дигән темага шигырь иҗат иткәнлеге дә билгеле. «Норлат (хәзерге Яшел Үзән) районы Мулла Иле авыл советы председателе белән секретаре, партия әгъзалары, бу ел мулла белән бер сафта торып, гает укыдылар» дигән хәбәргә нигезләнеп:

«...Мулла Иле авылы булсын да,
Коммунистлар динле булмасын.
Мулла Иленең һәрбер коммунисты
Алмашырлык авыл мулласын!..» – дип яза ул.

(«Чаян» журналының 1931 елгы гыйнвар санында «Һ.Т.» имзасы белән басылган.)

Тамырлары борынгылыкка киткән авыл үзе дә күренекле шәхесләр тәрбияләгән. Шагыйрь һәм рухани, сәясәтче, вәисевчеләр хәрәкәтен нигезләүче Баһаветдин Вәисев (1804–1893), аның уллары Гайнанетдин Вәисев (1878–1918) һәм Газизҗан Вәисев (1887–1937), тарихчы-галим-педагог Гыймади Хәйри (1912–1961), филология фәннәре докторы, профессор Гомәр Саттаров (1932–2021), РСФСРның халык мәгарифе отличнигы Равил Сәйфетдинов (1938–2018) Мулла Иленнән иде.

Кемнәр генә яшәп китмәгән дә, кемнәр генә яшәми авылымда. Бүген авылда 630 лап кеше теркәлгән. Кызганычка каршы, сугыш ветераннары инде мәрхүмнәр, тыл ветераннары да 5 кенә кеше калган. Авыл халкына сигезьеллык белем бирүче мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният үзәге, китапханә, фельдшер-акушер бүлеге хезмәт күрсәтә.



Монысы инде минем Туган йортым... Биш бала үскән йорт хәзер тынычланып, күңелсезләнеп калган шикелле. Шулай шул, бала-чага тавышыннан, умарта оясын хәтерләтеп, гөжләп торган йорт хәзер тынычлык кичерә. Сирәк-мирәк гаиләләребез белән өерелеп кайтканда гына яшьлегенә кайтып ала ул.

Туган якка булган мәхәббәт хисләре вакытлар үтү белән тирәнәя, байый, тулылана гына бара. Авылымның бай тарихы, мәдәнияте, нинди генә һөнәр иясе булуга карамастан, халкы, кече яшьтән үк тормышыбызның бер кисәгенә әверелә. Туган якны өйрәнү аны яратып яшәп калган кешеләрнең дә, аннан еракларга китеп көн күргәннәрнең дә горурланырлык матур эшләрен аңларга булыша.

2020 елда авыл тарихын тагын да тирәнрәк ачкан, яңа мәгълүматлар китерелгән «Илһам биргән җирем» дигән китап басылып чыкты. Китап авылыбыз тарихын гына түгел, төрле елларда матбугат битләрендә исемнәре телгә алынган тырыш, уңган кешеләре турындагы мәгълүматны да киләчәк буыннарга җиткерер. Әлеге җыентык бүгенгене киләчәк белән тоташтыручы бер күпер булып хезмәт итәр.

Дөнья картасы чуар. Ләкин кайларга гына таралышып яшәсәк тә, күңелебез белән без бик еш туган җиребезгә кайтабыз...

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА**